**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ**
**ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**

422370 г.Тетюши, ул.Малкина, 39

422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур, 39

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru
ОКПО 78702097, ОГРН 1061672000037, ИНН/КПП 1638004978/163801001

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**29 .07. 2025** **№ 67-1**

**Тәтеш муниципаль районы Советының 09.12.2024 елның 56-1 номерлы «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы бюджеты турында»карарына үзгәрешләр кертү хакында**
**(Тәтеш муниципаль районы Советының 24.02.2025 № 61-1; 29.04.2025 № 64-2; 27.05.2025 № 65-2; 30.06.2025 № 66-2 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән)**

Тәтеш муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе А. А. Богдановның «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы бюджеты турында» 09.12.2024 № 56-1 карарына үзгәрешләр кертү кирәклеге турындагы мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң (Совет карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Тәтеш муниципаль районы Советы 24.02.2025 № 61-1; 29.04.2025 № 64-2; 27.05.2025 № 65-2; 30.06.2025 № 66-2), Карар кабул итте:

1. Тәтеш муниципаль районы Советының «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы бюджеты турында» 09.12.2024 ел, № 56-1 карарына (Тәтеш муниципаль районы Советының 24.02.2025 ел, № 61-1; 29.04.2025 ел, № 64-2 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән; 27.05.2025 № 65-2; 30.06.2025 № 66-2) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 1 статьяда, 1 пунктта, 1 пунктчада «суммасында Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы бюджеты керемнәре күләме» сүзләреннән соң цифрлар
«1 164 372,13» саннарын «1 193 288,90»саннарына алмаштырырга;

1 статьяда, 1 пунктта, 2 пунктчада «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы бюджеты чыгымнары күләме» сүзләреннән соң цифрлар
«1 205 444,16» ны «1 234 360,93»саннарына алмаштырырга

2. Тәтеш муниципаль районы бюджетының калган акчаларын 01.01.2025 елга, ТР Финанслар министрлыгы белән килештереп, 13 140,15 мең сум күләмендә түбәндәге максатларга юнәлтергә:

- «Гомумдәүләт мәсьәләләре " тармагы буенча 7 892,11 мең сум күләмендә;
- «милли куркынычсызлык һәм хокук саклау эшчәнлеге " тармагы буенча 93,18 мең сум күләмендә;
- «мәдәният һәм кинематография» тармагы буенча 450,00 мең сум күләмендә;
- «массакүләм мәгълүмат чаралары " тармагы буенча 828,00 мең сум күләмендә;
- «Социаль сәясәт " тармагы буенча 2 400,00 мең сум күләмендә;
- 10 нчы кушымта нигезендә Тәтеш муниципаль районы җирлекләренә бюджетара трансфертлар бирү өчен 1 476,86 мең сум күләмендә.

Тәтеш муниципаль районы җирлекләренең җирле үзидарә органнары үз бюджетларында әлеге карарның 2 пунктының җиденче абзацында күрсәтелгән Тәтеш муниципаль районы бюджетыннан бюджетара трансфертларны исәпкә алырга тиеш.

3. 1,2,3,4,5,9,10 кушымталарының 1 таблицаларын яңа редакциядә бәян итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://tetushi.tatarstan.ru/ .

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Тәтеш муниципаль районы Советының бюджет, икътисад һәм эшкуарлык буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**башлыгы** **Р.Х. Сафиуллов**